**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 20 » 08 2021 № 267

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 елга халык өчен торак хезмәтләренә тарифлар турында»18.01.2021 ел, №8 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «ТР Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 елга халык өчен торак хезмәтләренә тарифлар турында» 18.01.2021 ел, №8 карары белән расланган күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлап алу турында карар кабул итмәгән социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннары наймы шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урынын карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләме» 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

   1.1. Түбәндәге эчтәлекле 7 һәм 8 пункт өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 7 | Вентиляцион каналларга техник хезмәт күрсәтү | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | | 0,39 |
| 8 | **Төтен юлларын техник хезмәт күрсәтү** | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | | 0,42 |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aksubayevo.tatarstan.ru урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының htth://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны ТР Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И.И.Исламовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.Ю.Зайцев